**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XI УТЫРЫШЫ**

# К А Р А Р № 20

Яңа Усы авылы «14» май 2021 ел

**«Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәсен оештыру тәртибе турында» 2015 елның 15 июнендәге 100 нче номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236 номерлы Россия Федерациясе Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәсен оештыру тәртибе турында» 2015 елның 15 июнендәге 100 нче номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 14 статьяның 14.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) инициативалы проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы: Г.С.Романова**